**Көзге халәт**

Көйсезләнеп тора көннәре,
Сизгән кебек күңел халәтен.
Көзге яңгыр кага тәрәзгә,
Яшермичә ачы яшьләрен.

Моңсулык биләгән җиһанны:
Күбрәк сагыш нуры күзләрдә.
Табигатькә генә түгел лә -
Кырау тигән күңелләргә дә.

Бер җылы сүз җитми төсле
Болыт артындагы кояшка.
Кешелек тә мохтаҗ бүген
Җылы сүзгә, назлы карашка.

Резедә Шәмсуллина, октябрь 2023 ел.